**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2020елның 12 августы** **51-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 декабрендәге 96-РС номерлы карары белән расланган үзгәрешләр кертелгән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 елның 12 декабрендәге 61-РС номерлы карары белән расланган«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә таянып, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең уңай яшәү шартларын, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Лаеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар уздыру чоры - кызыксынган затларга аларны үткәрү турында хәбәр итү мизгеленнән башлап, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылган көнгә кадәр хәбәр ителә дип билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан ким һәм өч айдан артык була алмый.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетына:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган иҗтимагый фикер алышуларның башлануы турында хәбәр әзерләргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 14 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртип нигезендә, әлеге Карарның 3.1 п. күрсәтелгән хәбәрне бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Әлеге Карарның 2 п. күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

3.4. гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне соңгы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә.

4. Әлеге карарны «Кама ягы» «Камская новь» район газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб - адресы һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Муниципаль район башлыгы-**
**Совет рәисе вазыйфаларын башкаручы** **Т.П.Борһанова**